ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяда “Юл эшчәнлеген планлаштыру” сүзләреннән соң “юл хәрәкәтен оештыру документлары,” сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 1 өлешендә “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы” сүзләреннән соң “, “Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль закон, “Юл хәрәкәте иминлеге турында” 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон” сүзләрен өстәргә;

3) 18 статьяда:
а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:
“$3^1$. Автомобиль юлы хуҗасының әлеге статьяның 1, 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән язма ризалыгы йә аны бирүдән дәлилләп баш тартуы автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан мондый ризалыкны бирү турында гариза кергән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча бирелә.”;
б) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:
“$3^2$. Автомобиль юлы хуҗасының әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән язма ризалыгын бирү тәртибе һәм аны бирү өчен кирәкле документлар исемлеге түбәндәгеләр тарафыннан билгеләнә:

1) вәкаләтле орган тарафыннан – региональ әһәмияттәге автомобиль юлларына карата;

2) җирле үзидарә органнары тарафыннан – җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата.”;

4) 20 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“20 статья. **Автомобиль юлларын юл сервисы объектлары белән тәэмин итү, стационар сәүдә объектларын автомобиль юлларына кушу таләпләре**”;

б) 7 өлештә “транспорт чараларын куеп тору һәм аларның тукталышы өчен мәйданчыклар” сүзләрен “транспорт чараларын куеп тору урыннары һәм аларның тукталышы өчен урыннар” сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлештә “Автомобильләр куеп тору һәм аларның тукталышы өчен мәйданчыкларны” сүзләрен “Транспорт чараларын куеп тору урыннарын һәм аларның тукталышы өчен урыннарны” сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 12 өлеш өстәргә:

“12. Әлеге статьяның 7 – 11 өлешләре нигезләмәләре автомобиль юлларына кушыла торган, гомуми мәйданы ун мең квадрат метрдан артык булган стационар сәүдә объектларына карата кулланыла.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 12 өлеше нигезләмәләре 2017 елның 16 декабренә кадәр файдалануга кертелгән, гомуми мәйданы ун мең квадрат метрдан артык булган стационар сәүдә объектларына карата кулланылмый, моңа керү, чыгу һәм килеп кушылу урыннарын, транспорт чараларын куеп тору урыннарын һәм аларның тукталышы өчен урыннарны, күчеш-тизлек полосаларын карап тотуга кагылышлы таләпләр керми.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда аларның үз көчләренә керүенең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары 2018 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2018 елның 28 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * ГОМУМИ БҮЛЕК * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 21-ТРЗ